**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 24 декабрендәге «Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» ПР-272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексының 39_28 һәм 39_29 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 30 гыйнварындагы 12-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 24 декабрендәге ПР-272 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 15 пунктка түбәндәге эчтәлекле 22-24 пунктчалар өстәргә:

«22) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен, һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә, әлеге Кодексның 39_28 статьясындагы 1 пунктының 3_1 бүлегендә каралган очракта, хосусый милектәге элекке җир кишәрлеге мәйданы, мондый яңадан бүлү территорияне ызанлауның расланган проекты яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлгәндә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш, башлангыч җир кишәрлеге мәйданы «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль закон белән җайга салына;

23) Россия Федерациясе Җир кодексының 39_28 статьясындагы 1 пунктының 3_1 пунктчасында каралган нигез буенча хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен элек күрсәтелгән нигез буенча яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү карала;

24) Россия Федерациясе Җир кодексының 39_28 статьясындагы 1 пунктының 3_1 пунктчасында каралган нигез буенча әлеге пунктның 23 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән бүленү яисә берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килгән хосусый милектәге җир кишәрлеген яңадан бүлү күздә тотыла.";

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева